| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2022 Казан ш. № 498-88/тэ-2022

«Тепло» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан куллanучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 03.11.2021 №200-27/тэ-2021 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя куюю турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 16 ноябрендәге 37-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023 елга җайга салынулы оешманың кирәкле планлаштырылган тулай табышын тәгаенләштереп, 2023 елга җылылык энергиясенә (егәрлегенә) озак сроклы тарифларга үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Тепло» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2022-2024 елларга тарифлар билгеләү турында» 03.11.2021 №200-27/тэ-2021 карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге таблица графаларын:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «01.01.2022 башлап | 1445,54 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 30.06.2022 кадәр | | | | | | |
| 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 1504,02 | - | - | - | - | -» |

2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге таблица графаларын:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 1504,02 | - | - | - | - | - |
| 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1539,23 | - | - | - | - | -» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 1601,78 | - | - | - | - | -». |

2. Әлеге карар белән үзгәреш кертелгән 2023 елга тариф 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев